МИНИСТЕРСТВО КУЛЬТУРЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘДӘНИЯТ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

22.02.2017 г. Казань № 167 од

Ачык республика киносценарийлар конкурсы үткәрү турында

БОЕРАМ:

1. Ачык республика киносценарийлар конкурсы (алга таба - Конкурс) турындагы Нигезләмәне (тәкъдим ителә) расларга.

2. Кинематография секторына (Л.Р.Гыйльметдинова) Конкурска әзерлек һәм аны үткәрү эшләрен оештырырга.

3. Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Министр А.М.Сибагатуллин

Татарстан Республикасы
Мәдәният министрлыгының
22 02 2017
№ 167 од
боерыгы белән расланган

Ачык республика киносценарийлар конкурсы турында
НИГЕЗЛӘМӘ

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Ачык республика киносценарийлар конкурсын (алга таба – Конкурс) гамәлгә куючы һәм оештыручы булып Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы (алга таба – Министрлык) тора.

1.2. Конкурс ел саен түбәндәге номинацияләр буенча үткәрелә:

тулы метражлы уен фильмына иң яхшы киносценарий;

кыска метражлы уен фильмына иң яхшы киносценарий.

1.3. Конкурсның приз фонды Министрлыкның керемнәр һәм чыгымнар җыелма сметасында каралган акчалар хисабына финанслана.

2. Конкурс үткәрүнең максатлары һәм бурычлары

2.1. Конкурс үткәрүнең төп максаты - профессионаллар һәм башлап язучы авторлар арасында талантлы киносценаристларны барлау, шулай ук Татарстан Республикасында киносценарийлар язу осталыгын үстерергә ярдәм итү.

2.2. Конкурс үткәрүнең төп бурычы булып милли фильмнар төшерү өчен милли киносценарийлар портфеле булдыру тора.

3. Конкурста катнашучылар

3.1. Конкурста әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән срокларда киносценарий һәм әлеге Нигезләмәнең кушымтасында китерелгән формада тутырылган гариза тапшырган, киносценарийны тапшырган мизгелдә 18 яше тулган, эшкә сәләтле затлар катнаша ала (алга таба - Катнашучылар).

4. Проектка куелган таләпләр

4.1. Конкурска киносценарийлар рус яки татар телләрендә (киносценарий татар телендә язылган булса, рус теленә тәрҗемәсе дә сорала) кабул ителә.

4.2. Конкурста катнашу өчен Конкурста катнашу турында гариза һәм тулы сценарий пакеты – киносценарий тексты, синопсис, автор турында кыскача резюме (тулы исеме, туган елы һәм урыны, башкарылган эшләре күрсәтелгән сценарийлар язу тәҗрибәсе тасвирламасы, элемтә өчен мәгълүмат: телефон номеры, электрон почта адресы, яшәү адресы, паспорт мәгълүматы) тапшырыла.

4.3. Киносценарийны Конкурска бары тик киносценарийның авторы гына тапшырырга хокуклы. Конкурска бер автордан бердән дә артык булмаган тулы метражлы фильм киносценарие һәм бер кыска метражлы фильм киносценарие кабул ителә.

4.4. Конкурска фильм төшерелгән яисә фильм төшерелә башлаган киносценарийлар, моңа охшаш конкурсларда призлар алган киносценарийлар, автордашлар иҗаты булган киносценарийлар (Катнашучының гариза белән бергә барлык автордашларының әлеге Нигезләмә шартлары буенча Конкурска катнашырга язмача ризалыгын тапшыру очрагы искәрмә булып тора) кертелми.

4.5. Конкурска тапшырылган киносценарий түбәндәге таләпләргә җавап бирергә тиеш:

Жанры: теләсә нинди;

Күләме: тулы метражлы уен фильмы өчен Times New Roman 14 стандарт шрифты белән А4 форматында 50 биткә кадәр, кыска метражлы уен фильмы өчен Times New Roman 14 стандарт шрифты белән А4 форматында 20 биткә кадәр;

Әзерлек дәрәҗәсе: әзер киносценарий;

Вакыйга урыны: Татарстан Республикасы.

Сюжетка таләпләр: актуаль проблемалы динамик сюжет. Бу көтелмәгән хәл яки күренеш, уникаль вакыйга булырга мөмкин. Төгәл диалоглар, чын персонажлар һәм төенләнеш, үсеш, кульминациядән торган анык драматургия структурасы хуплана. Төп геройлар теләсә нинди яшьтәге ир кешеләр һәм хатын-кызлар, егетләр һәм кызлар, яшүсмерләр, балалар һәм җәнлек-җанвар була ала.

Бөтен текстларның датасы (язылу елы күрсәтелеп) куелган булырга тиеш.

Конкурска юлланган киносценарийлар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Киносценарий булмаган очракта синопсис үзе генә каралмый.

## 5. Конкурс комиссиясе

5.1. Конкурс комиссиясе (алга таба – Комиссия) тугыз кешедән тора һәм Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы боерыгы белән раслана, аңа Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы вәкилләре, Татарстан

Республикасының танылган мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшлеклеләре һәм башка чакырылган затлар кертелә, аның Рәисе, Рәис урынбасары һәм җаваплы секретаре була.

5.2. Комиссия эше белән Рәис идарә итә. Ул югында аның вазыйфасын урынбасары үти. Комиссия өстәмә рәвештә экспертлар чакыру хокукына ия. Конкурс нәтиҗәләре белән шәхсән кызыксынучы кеше комиссия әгъзасы була алмый.

5.3. Комиссия эше утырышларда башкарыла. Комиссиянең барлык әгъзаларының өчтән икесе катнашса, утырыш вәкаләтле булып санала. Комиссиянең җаваплы сәркатибе тавыш хокукына ия түгел.

5.4. Комиссиянең җаваплы сәркатибе түбәндәге функцияләрне үти:

- әлеге Нигезләмәнең 4.1-4.5 пунктларында билгеләнгән таләпләрне искә тотып документларны кабул итә һәм теркәп куя, аларның саклануын тәэмин итә.
- Комиссия утырышларын оештыра, документлар әзерли һәм беркетмәләрне рәсмиләштерә.

5.5. Комиссия карарлары утырышта катнашкан әгъзаларының ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә, рәислек итүче һәм җаваплы секретарь имзалаган беркетмә белән рәсмиләштерелә. Тавышлар тигез булган очракта Рәиснең тавышы хәл итә.

## 6. Киносценарийларны бәяләү критерийлары

6.1. Киносценарийларны бәяләү критерийлары:

проектның Конкурс шартларына туры килүе;

идея-сәнгати әһәмияте;

сценарийның төп идеясенең, автор позициясенең үзенчәлеге;

форма һәм эчтәлекнең бер бөтенлеге;

теманың актуальлеге һәм социаль әһәмияте;

хәтердә калырлык характерлар һәм эшкәртелгән диалоглар булуы;

куелу потенциалы - киносценарий бүгенге киностудияләрне ни дәрәҗәдә кызыксындырачак.

6.2. Комиссия киносценарийларны һәр номинация буенча 6.1 пунктында күрсәтелгән критерийлардан чыгып ун баллы система буенча бәяли.

Һәр критерий буенча баллар куела һәм алар кушыла. Һәр номинациясендә баллар суммасы күрсәткече буенча беренче урын алган Катнашучы Конкурс җиңүчесе дип таныла.

Балларның сумма күрсәткече тигез булган очракта, әлеге Нигезләмәнең 5.5 пунктында күрсәтелгән тәртиптә тавыш бирү юлы белән Комиссия карары кабул ителә һәм Конкурс җиңүчесе билгеләнә.

## 7. Конкурсны үткәрү шартлары һәм тәртибе

7.1. Министрлык Конкурсны үткәрү турындагы карарны аны үткәрү датасына кадәр 10 көн алдан кабул итә. Әлеге карар кабул ителгәннән соң өч көн эчендә Министрлыкның рәсми сайтында (www.mincult.tatarstan.ru) “Фестивальләр. Конкурслар. Грантлар. Премияләр” бүлегендә Конкурс турында мәгълүмат урнаштырыла, анда Министрлыкның Конкурсны үткәрү турындагы карары, Конкурсны үткәрү датасы, вакыты һәм урыны, Конкурска документлар пакетын кабул итү башлану һәм тәмамлану датасы һәм вакыты; Конкурска тәкъдим ителгән документларны карау вакыты һәм Конкурска нәтиҗәләр чыгару датасы; җиңүчеләрне бүләкләү датасы, вакыты һәм урыны турында мәгълүмат була.

7.2. Конкурска бер генә гариза тапшырылган яки бөтенләй тапшырылмаган очракта Конкурс үткәрелмәгән дип таныла.

7.3. Министрлыкка Конкурска әлеге Нигезләмәнең 7.1 пункты нигезендә урнаштырылган мәгълүматта күрсәтелгән вакыт аралыгында бу Нигезләмәнең 3нче бүлеге нигезендә тулы сценарий пакеты тәкъдим ителә.

7.4. Комиссия утырышы беркетмәсе нигезендә биш эш көне эчендә Конкурс җиңүчеләре билгеләнүе турында Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы боерыгы чыгарыла.

7.5. Конкурс йомгаклары турында мәгълүмат боерык имзаланганнан соң бер атна эчендә Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының рәсми сайтына www.mincult.tatarstan.ru урнаштырыла

7.6. Конкурс җиңүчеләре киносценарий хокукларын, Россия Федерациясе Гражданлык кодексының 1285 маддәсенә туры китереп, хокуктан читләшү турында килешү нигезендә, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына бирергә хокуклы.

## 8. Приз фонды

8.1. Конкурс җиңүчесе – тулы метражлы уен фильмына иң яхшы киносценарий авторы 70 000 сум (җитмеш мең сум 00 тиен) күләмендә акчалата бүләккә ия була.

8.2. Конкурс җиңүчесе – кыска метражлы уен фильмына иң яхшы киносценарий авторы 30 000 сум (утыз мең сум 00 тиен) күләмендә акчалата бүләккә ия була.

Ачык республика
киносценарийлар
конкурсы турында
Нигезләмәгә кушымта

Ачык республика киносценарийлар конкурсында
КАТНАШУ ГАРИЗАСЫ

1. Ачык республика киносценарийлар конкурсы турында Нигезләмә белән танышып,
_______________________________________________________________
(Катнашучының Ф.И.Әи)
Нигезләмәдә билгеләнгән шартларда Ачык республика киносценарийлар конкурсында катнашу ниятемне белдерәм һәм катнашу өчен әлеге гаризаны юллыйм*.
2. Проектның номинациясе:_________________________ ___________________,
3. Проектның исеме:_____________________________________________________,
4. Гамәлдәге яшәү урыны: ________________________________________________,
5. Элемтә өчен телефон номеры:___________________________ ___________,
6. Электрон почта адресы:_______________________________________________,

*“*Персональ мәгълүматлар турында*” *27.07.2006 ел, №152-ФЗ Федераль законга туры китереп, әлеге гаризага беркетелгән персональ мәгълүматны эшкәртергә рөхсәт бирәм.*

_____________(______________________)
(имза)